СОВЕТ
СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д. 52, с. Старое Чурилино,
Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яңа урам, 52 йорт, Иске Чүриле авылы,
Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48,3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Shur.Ars@tatar.ru

**Иске Чүриле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«04» июнь 2024 ел** **№ 90**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр кертү проекты турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законга, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы рәвештә Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Иске Чүриле авыл җирлеге Советының 23.04.2021 ел, № 20 карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына (03.10.2022 №55, 25.10.2023 №78 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 1 өлешендә 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру»;

2) 19 статьяның 5 пунктының 2 абзацында «1-7 пунктлары белән» сүзләрен «1-7 һәм 9_2 пунктлары белән» сүзләренә алыштырырга.

3) 51 статьяның 1пункты 4 пунктчасының 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм

законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чаралар эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыра һәм гамәлгә ашыра;».

4) 42 статьяның 1 пункты түбәндәге эчтәлектәге 10.1 пунктча белән тулыландырырга:

«10.1) аның чит ил агенты статусын алуы;»;

5) 73 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«73 статья. Муниципаль норматив хокукый актларны, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләрне бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керү тәртибе.

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге оештыручы булып торган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актның, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең рәсми игълан ителүе булып түбәндәгеләр тора:

1) Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында тулы текстны рәсми рәвештә бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru; массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык ЭЛ №ФС77-60244 бирелгән 17.12.2013 Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте тарафыннан (Роскомнадзор) яки «Арча хәбәрләре» («Арский вестник») Арча район газетасында (ММЧны теркәү турында таныклык, Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан Эл № ФС77–47527 30.11.2011 елда бирелгән);

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында (https://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру.

Искәрмәләр:

а) җирлек уставында тиешле җирлекнең рәсми сайты күрсәтелә,

муниципаль район/шәһәр округы уставында район/округның рәсми сайты;

б) торак пунктларның ихтыярына шулай ук түбәндәге ысул күрсәтелә:

«3) Татарстан Республикасы, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Новая урамы, 52 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Венета авылы, Школьная урамы, 3 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Ашабаш авылы, Комсомольская урамы, 4а йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Штерә авылы, Советская урамы, 30Б йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру.».

3. Гражданнарның Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен Иске Чүриле авылы, Новая урамы, 52 йорт; Венета авылы, Школьная урамы, 3 йорт; Ашабаш авылы, Комсомольская

урамы, 4а йорт; Штерә авылы, Советская урамы, 30Б йорт адреслары буенча «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренә тоташу пунктлары эшли.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, муниципаль хокукый актлардан яки Федераль закон белән чикләнгән мәгълүматлар булган аерым нигезләмәләрдән тыш, имзаланганнан соң 7 көн эчендә игълан ителә.

5. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексына ярашлы рәвештә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр акт үзе башканы билгеләмәсә, имзаланган көннән үз көченә керә.

7. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның домен исемнәре һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары сыйфатында теркәү турында мәгълүматлар күрсәтелгән вакытлы басмалар, челтәр басмалары исемлеге, анда муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне игълан итү (рәсми рәвештә бастырып чыгарудан тыш) «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерелә».

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибен 1 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү һәм гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибен 2 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына килгән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

1) Сафиуллин Айдар Харис улы-1 нче Иске Чүриле сайлау округы буенча депутат;

2) Гарифуллин Рамиль Харис улы-4 нче Иске Чүриле сайлау округы буенча депутат;

3) Хамидуллин Рамиль Сәубән улы – 3 нче Иске Чүриле сайлау округы буенча депутат.

6. Иске Чүриле авыл җирлеге Советы депутатларының уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына тәкъдимнәре 2024 елның 2 июленә кадәр эшче төркемгә кертелә дип билгеләргә.

7. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына гражданнарның тәкъдимнәре эшче төркемгә язма рәвештә, авторның ф.и. а.и., туган елы, адресы күрсәтелеп, Иске Чүриле авылы, Новая урамы, 52 йорт адресы буенча җибәрелә

дип билгеләргә.

8. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гавами тыңлауларны Иске Чүриле авыл мәдәният йорты бинасында 2024 елның 03 июлендә 16.00 сәгатькә билгеләргә.

9. Эшче төркемгә, Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына Иске Чүриле авыл җирлеге Советы депутатларының төзәтмәләрен һәм гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнеп һәм гомумиләштереп, аны 2024 елның 05 августына кадәр Иске Чүриле авыл җирлеге Советы каравына кертергә.

Иске Чүриле авыл җирлеге
башлыгы урынбасары И.Н. Габдрахманов

Иске Чүриле авыл
җирлеге Советының
04.06.2024 ел, № 90
карарына 1 нче кушымта

**«Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе**

1. Татарстан Республикасы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына тәкъдимнәр язма рәвештә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә Иске Чүриле авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 422014, Татарстан Республикасы, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Новая урамы, 52 йорт.

| № | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Проектның төзәтмәне исәпкә алган тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.А.и., адресы, эш яки уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Бу тәкъдимнәр Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында эш көннәрендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар 422014, Татарстан Республикасы, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Новая урамы, 52 йорт адресы буенча язма рәвештә яки почта аша бирелә.

Гаризалар гавами тыңлаулар уздырылганчы 7 көннән дә соңга калмыйча эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре эшче төркем тарафыннан теркәлә һәм карау өчен «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советына һәм башлыгына тапшырыла.

Иске Чүриле авыл
җирлеге Советының
04.06.2024 ел, № 90
карарына 2 нче кушымта

**«Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе**

1. «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектын карау буенча гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставының 22 статьясына ярашлы рәвештә үткәрелә.

2. Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, прокуратура, белгечләр, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре, белгечләр, кызыксынган затлар чакырылып үткәрелергә мөмкин.

3. Гавами тыңлауларда «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең теләсә кайсы кешесе катнашырга хокуклы.

4. Катнашучыларны теркәү гавами тыңлаулар башланганчы 1 сәгать алдан башлана.

5. Гавами тыңлауларда «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы рәислек итә.

6. Гавами тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул катнашучыларга фикер алышу мәсьәләләренең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, килгән тәкъдимнәрне исәпкә алу өчен секретариат җитәкчесе һәм ике әгъза составында гавами тыңлаулар секретариаты сайлана.

8. Төп чыгыш белән устав проектын эшләү буенча эшче төркем җитәкчесе чыгыш ясый.

9. Төп чыгыштан соң сүз гавами тыңлауларда катнашу өчен чакырылган катнашучыларга бирелә.

10. Гавами тыңлауларда катнашучылар, чыгыш ясау хокукы белән гариза бирү вакытына бәйле рәвештә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен, чират буенча чакырыла.

11. Гавами тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары расланган регламент нигезендә дәвам итәргә тиеш.

12. Гавами тыңлауларда катнашучылар чыгыш тәмамланганнан соң чыгыш ясаучыларга сораулар бирергә хокуклы.

13. Гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

14. Гавами тыңлаулар үткәргәндә тәртип саклау гавами тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

15. Гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны тыңлаулар уздырыла торган бинадан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

16. Чыгышлар тәмамлангач, рәислек итүче гавами тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә гавами тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәрне, киңәшләрне төгәлләү өчен сүз бирә ала.

17. Гавами тыңлауларда катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре гавами тыңлаулар беркетмәсенә кертелә. Гавами тыңлаулар беркетмәсенә секретариат җитәкчесе һәм әгъзалары кул куя һәм ул Иске Чүриле авыл җирлеге Советы материалларында билгеләнгән тәртиптә саклана.

18. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә гавами тыңлаулар секретариаты тарафыннан әзерләнә һәм игълан ителергә тиеш.

19. Гавами тыңлауларны оештыру һәм матди-техник тәэмин итү Иске Чүриле авыл җирлеге Советы тарафыннан башкарыла.